ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 8 07 декабрь 2021 ел

2022 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегендәге
Иске Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, 2019 елның 28 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 14 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 22 декабрендә 14.00 сәгатьтә “Иске Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБББУ бинасы янында,Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Иске Урыссу торак пункты, Мәктәп урамы, 45Б йорт адресы буенча 2022 елда Ютазы муниципаль районы Иске Урыссу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән,көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Иске Урыссу торак пунктындагы Октябрь, 1 Май урамнарындагы юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, түшәү, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Иске Урыссу торак пунктында хәтер скверы төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәткә түләү, төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу, скверның нигезен төзү, мемориал сатып алу һәм аны урнаштыру, килешү нигезендә эш өчен түләү);

- зиратның коймасын алмаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча түләү);

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Урыссу авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова